КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 июль г.Казань № 667

2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында булган L-410 самолеты һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр чыгымнарын каплау расходларын гамәлгә ашыру максатларында 2022 елда Минзәлә муниципаль районы бюджетына һәм Яр Чаллы шәһәре бюджетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында булган L-410 самолеты һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр чыгымнарын каплау расходларын гамәлгә ашыру максатларында 2022 елда Минзәлә муниципаль районы бюджетына һәм Яр Чаллы шәһәре бюджетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 11 июль, 667 нче
карары белән расланды

2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында булган L-410 самолеты һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр чыгымнарын каплау расходларын гамәлгә ашыру максатларында 2022 елда Минзәлә муниципаль районы бюджетына һәм Яр Чаллы шәһәре бюджетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында булган L-410 самолеты һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр чыгымнарын каплау расходларын гамәлгә ашыру максатларында 2022 елда Минзәлә муниципаль районы бюджетына һәм Яр Чаллы шәһәре бюджетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба –шул ук эзлеклелектә самолет һәлакәте, муниципаль берәмлек, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар 2022 елда бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарның юнәлешләренә самолет һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр чыгымнарын каплау керә.

4. Муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

самолет һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә субсидия бирү тәртибен, шулай ук һәлак булганнарны күмүне оештыру, үткәрү һәм аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып бару буенча юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең хезмәт күрсәтүләре исемлеген билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) гамәлгә ашыру максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен кертеп) булу;

Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча гамәлгә ашыру максаты белән башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы йөкләмәләре каралган башка бюджетара трансферт бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү һәм Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

5. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларның бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән раслана.

6. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече – самолет һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруга, үткәрүгә, аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия алучы дип танылган юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең саны.

7. Бюджетара башка трансферт алу өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

башка бюджетара трансфертка ихтыяҗ булуның финанс-икътисадый нигезләвен теркәп, ирекле формада башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка);

муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органының агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турындагы карарыннан самолет һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына кадәр транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләрнең чыгымнарын каплау буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен муниципаль берәмлек бюджетында бюджет ассигнованиеләренең булуын раслый торган өземтә;

бу Тәртипнең 4 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль хокукый акт күчермәсен.

8. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган җиде көн эчендә карап тикшерә;

заявка теркәлгән көннән 15 эш көне эчендә башка бюджетара трансферт бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

башка бюджетара трансферт бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көн эчендә башка бюджетара

трансферт бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында язма хәбәр бирә.

9. Башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансферт бирү шартларының үтәлмәве;

бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

бу Тәртипнең 7 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

10. Башка бюджетара трансферт Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

3.6. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансферт күләме;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәсе;

башка бюджетара трансфертны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансферт торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турында хисаплар бирү сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең билгеләнгән мәгънәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансферттан файдалану йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның Килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

9. i муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертның күләме (Ci) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = K_i \times P_i,$$

монда:

$K_i$ – бу Тәртипнең кушымтасында күрсәтелгән i муниципаль берәмлектә самолет һәлакәте аркасында һәлак булган затлар саны, берәмлек;

$P_i$ – i муниципаль берәмлектә юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең самолет һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыру һәм үткәрү, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына кадәр транспорт белән алып бару чыгымнарының 1 затка уртача нормативы:

Минзәлә муниципаль районында – 28 500,0 сум;

Яр Чаллы шәһәрендә – 60 615,6 сум.

13. Башка бюджетара трансферт Министрлык тарафыннан Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

14. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы 2023 елның 20 гыйнварына кадәр Министрлыкка Килешүдә каралган тәртип нигезендә һәм форма буенча түбәндәгеләрне тапшыра:

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансферт торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап;

башка бюджетара трансфертны файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турында хисап.

15. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан Килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәләрен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

16. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы бу Тәртипнең 14 пункты нигезендә тапшырыла торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

17. 2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2023 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемена түләтелергә тиеш.

18. 2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, башка бюджетара трансферт муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына 2023 елның 1 апреленә кадәр тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

19. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органнарына карата бу Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Башка бюджетара трансферттан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

20. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында булган L-410 самолеты һәлакәте аркасында һәлак булганнарның җеназасын оештыруны, үткәрүне, шулай ук аларның гәүдәләрен күмү урынына транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр чыгымнарын каплау расходларын гамәлгә ашыру максатларында 2022 елда Минзәлә муниципаль районы бюджетына һәм Яр Чаллы шәһәре бюджетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә
кушымта

2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районында булган L-410 самолеты һәлакәте аркасында
һәлак булган, юридик затлар, (яки) индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан
аларга карата җеназасын оештыру, үткәрү, шулай ук күмү урынына транспорт белән
алып бару чыгымнары гамәлгә ашырылган затлар саны

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Затлар саны |
|---|---|---|
| 1. | Минзәлә муниципаль районы | 2 |
| 2. | Яр Чаллы шәһәре | 16 |
| | Барлыгы | 18 |

_______________________________________